КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 2 май г.Казань № 557

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга «Бәхетле балачак» балалар үзәге» балаларга өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында» 2022 ел, 2 сентябрь, 954 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга «Бәхетле балачак» балалар үзәге» балаларга өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында» 2022 ел, 2 сентябрь, 954 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «балаларга» сүзен төшереп калдырырга;

1, 2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2023 елга «Бәхетле балачак» балалар үзәге» өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан өстәмә гомуми үстерү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны;

2023 елга «Бәхетле балачак» балалар үзәге» өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан өстәмә гомуми үстерү программаларын тормышка ашыру күләмнәрен;

2023 елга «Бәхетле балачак» балалар үзәге» өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан «дәүләт (муниципаль) милкендәге мөлкәтне карап тоту (эксплуатацияләү)» дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны.

2. «Бәхетле балачак» балалар үзәге» өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү күләменә карата төзәтү коэффициентын 1,1618 күләмендә билгеләргә.»;

әлеге карар белән расланган 2023 елга «Бәхетле балачак» балалар үзәге» балаларга өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан өстәмә гомуми белем бирүче гомуми үстерү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2023 елга «Бәхетле балачак» балалар үзәге» өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан өстәмә гомуми үстерү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар»;

әлеге карар белән расланган 2023 елга «Бәхетле балачак» балалар үзәге» балаларга өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан өстәмә гомуми белем бирүче гомуми үстерү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү күләмнәре исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2023 елга «Бәхетле балачак» балалар үзәге» өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан өстәмә гомуми үстерү программаларын тормышка ашыру күләмнәре»;

әлеге карар белән расланган 2023 елга «Бәхетле балачак» балалар үзәге» балаларга өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесе милкендәге мөлкәтне карап тотуга (эксплуатацияләүгә) дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 2 сентябрь, 954 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 2 май, 557 нче
карары редакциясендә)

2023 елга «Бәхетле балачак» балалар үзәге» өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан «дәүләт (муниципаль) милкендәге мөлкәтне карап тоту (эксплуатацияләү)» дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнар

| Дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнар, мең кв.метрга сум | Эш күләме, мең кв.метр |
|---|---|
| 1 948 327,6 | 1,9930 |

---